**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Югары Сәрдә авыл җирлеге Советы Карары**

22 апрель 2019 ел № 93

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Советының «Физик затларның милкенә салым турында» 2014 елның 10 ноябрендәге 70 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Советының 2014 елның 10 ноябрендәге 70 номерлы «физик затлар милкенә салым турында» гы карарына (2015 елның 3 июнендәге 98 номерлы, 2015 елның 19 октябрендәге 5 номерлы, 2018 елның 2 июлендәге 75 номерлы, 2019 елнын 9 мартындагы 90 номерлы редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. карарның 4.1 пунктындагы 6 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

"Салым ташламасына хокукны раслаучы документлар рәтенә керә:

- йорт кенәгәсеннән өземтә;

- әлеге салым буенча салым түләүче дип танылган физик затның шәхесен раслаучы документ;

- аның исеменә бирелгән күп балалы гаилә таныклыгы яки ул ата-ана (уллыкка алучы) булган балаларның туу турындагы таныклыгы.».

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырырга.

3.Әлеге карар 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Югары Сәрдә авыл башлыгы Р.Р.Хөснетдинов